Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенько авыл җирлегенең Тәмте авылында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында гражданнар җыены карары

2024 елның 22 ноябре №7__

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авылында гражданнар җыены карар кабул итте::

1.2025 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлегенең Тәмте авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 300,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.:

- Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Тәмте авылы, 2 нче Октябрь ур., мәдәният йорты бинасы;
- ТР Кама Тамагы районы Тәмте авылы Октябрь урамы, 88а йорт, авыл җирлеге администрациясе бинасы; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Тәмте
авыл җирлеге башлыгы: И.А.Зиновьев